# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«18 » 03 2019 ел Яр Чаллы №977

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль районының архив бүлеге биналарында янгын куркынычсызлыгы чаралары турында инструкцияне раслау хакында

Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2009 елның 12 январендәге 3 санлы приказы белән расланган Россия Федерациясе дәүләт һәм муниципаль архивларында янгын куркынычсызлыгының махсус кагыйдәләре таләпләре, шулай ук «Янгын сүндерү техникасы. Ут сүндергеч. Куллануга таләпләр» кагыйдәләр җыелмасы нигезендә (СП 9.13130.2009)

## КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль районының архив бүлеге биналарында янгын куркынычсызлыгы чаралары турында инструкцияне расларга.

2. Әлеге карар үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ю. Шакировага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов

РАСЛЫЙМ:
Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе

_______________ Л.Г. Авзалов

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль районының архив бүлеге биналарында янгын куркынычсызлыгы чаралары турында инструкция**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Инструкция Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2009 елның 12 январендәге 3 санлы приказы белән расланган Россия Федерациясе дәүләт һәм муниципаль архивларында янгын куркынычсызлыгының махсус кагыйдәләре таләпләре, шулай ук «Янгын сүндерү техникасы. Ут сүндергеч. Куллануга таләпләр» кагыйдәләр җыелмасы нигезендә (СП 9.13130.2009) эшләнгән һәм Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль районының архив бүлеге биналары өчен кулланыла, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен, архивта янгын чыккан очракта гамәлләр тәртибен билгели һәм янгын куркынычсызлыгы өчен җаваплы хезмәткәрләр, архив биналары хезмәткәрләре тарафыннан өйрәнү һәм үтәү өчен мәҗбүри булып тора.

1.2. Архивның янгын куркынычсызлыгы янгынны булдырмый калу һәм янгыннан саклау системалары, шул исәптән оештыру-техник чаралар белән тәэмин ителергә тиеш.

1.3. Архив хезмәткәре, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозу очраклары ачыкланганда, бу хакта җитәкчелеккә хәбәр итәргә, шулай ук күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерү өчен мөмкин булган чараларны күрергә тиеш.

1.4. Архивның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, архив хезмәткәрләрен Россия Федерациясе законнары нигезендә укытуны оештыру һәм тәэмин итү өчен җаваплы булып аларның җитәкчеләре тора.

1.5. Архив хезмәткәрләренә, җитәкчеләрне дә кертеп, янгын куркынычсызлыгы чаралары буенча уку үтәч кенә эш башларга рөхсәт ителә.

Янгын куркынычсызлыгы чаралары буенча укыту Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2007 елның 12 декабрендәге 645 санлы приказы белән расланган «Оешма хезмәткәрләрен янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү» Янгын куркынычсызлыгы нормалары нигезендә уздырыла.

1.6. Көн саен архив эше тәмамланганнан соң, биналар әлеге Инструкция белән билгеләнгән тәртиптә карала. Карау барышында янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозу очраклары ачыкланганда, аларны бетерү буенча чаралар күрергә кирәк. Ачыкланган янгын куркынычсызлыгы

таләпләрен бозуларны мөстәкыйль рәвештә бетереп булмаганда, бу турыда архив җитәкчесенә җиткерерү һәм бинаны карау журналында тиешле язу зарур.

## II. Архив биналарын карап тотуга янгын куркынычсызлыгы таләпләре

2.1. Архив бүлеге биналары урнашкан бинага янгын сүндерү машиналарының ирекле керү мөмкинлеге тәэмин ителә. Керү юллары һәм подъездлар материаллар, җиһазлар һәм автотранспорт кую өчен файдаланылырга тиеш түгел.

Төп һәм запас чыгу юллары һәм тышкы янгын баскычларына узу, янгыннар һәм янгын сүндерү турында хәбәр чараларына бару юллары һәрвакыт ирекле булырга һәм төнге вакытта яктыртылырга тиеш. Подъездлар һәм керү юллары кышкы вакытта кардан даими чистартылып торырга тиеш.

2.2. Куллану процессында янгыннан саклау системаларын карап тотуны һәм эшкә яраклылыгын проект һәм техник документация таләпләре нигезендә тәэмин итәргә кирәк. Конструктив, күләмле-планлаштыру һәм инженер-техник үзгәрешләр, шулай ук биналарның функциональ билгеләнешен үзгәртү, янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документ таләпләрен үтәүне исәпкә алып, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнар нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш.

Ут белән эш йөртү, эретеп ябыштыру, кисү, буяу һәм башка янгын куркынычы булган эшләрне Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2003 елның 18 июнендәге 313 санлы карары белән расланган Россия Федерациясендә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре нигезендә үткәрергә кирәк. Янгын куркынычы булган эшләрне башкарганда, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тоту җитәкче тарафыннан билгеләнгән зат тарафыннан башкарыла.

Биналарны, инженерлык җиһазларын һәм янгынга каршы саклау системаларын ремонтлау белән бәйле эшләрне кабул итү тәртибе, әгәр башкасы Россия Федерациясенең закон, норматив хокукый актлары һәм янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документлар белән каралмаган булса, җитәкче тарафыннан билгеләнә.

2.3. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2003 елның 18 июнендәге 314 санлы карары белән расланган «Биналарны□ һәм тышкы җайланмаларны□ янгын чыгу һәм янгын куркынычызлыгы буенча категорияләрен билгеләү» янгын куркынычсызлыгы нормаларында билгеләнгән методика буенча архив саклагычлар өчен аларны□ янгын чыгу һәм янгын куркынычызлыгы буенча категорияләре билгеләнергә тиеш.

2.4. Янгын куркынычсызлыгы таләпләренә туры килү сертификатлары булмаган җиһазларны, эшләнмәләрне, матдәләрне һәм материалларны куллану һәм саклау рөхсәт ителми (мондый сертификатлар булу мәҗбүри булган очракларда).

2.5. Уку залына килүчеләр саны, янгын вакытында кешеләрне куркынычсыз эвакуацияләүне тәэмин итү шартларыннан чыгып, уку залыны□ рөхсәт ителгән сыйдырышлылыгыннан артмаска тиеш.

2.6. Архив биналарында тәмәке тарту тыела.

2.7. Архив саклагычларда һәм хезмәт биналарында тыела:

- биналарны җыештырганда тиз янып китүчән сыеклыклар һәм янучан сыеклыклар куллану;
- туңган сусүткәргеч торбаларны, канализация торбаларын һ.б. ачык ут белән җылыту;
- торак урыннар булдыру һәм гражданнарның вакытлыча яшәвенә юл кую.

2.8. Ишекләрне мөстәкыйль ябу җайланмалары төзек хәлдә булырга тиеш.

2.9. Стеналар, түшәмәләр һәм киртәләү конструкцияләре төрле инженерлык коммуникацияләре белән кисешкән урыннарда барлыкка килгән тишекләр һәм ярыклар төзелеш эремәсе яки башка янмый торган материаллар белән капланырга тиеш.

2.10. Архив саклагычларда һәм хезмәт биналарында түбәндәге язулар белән табличкалар урнаштырылырга тиеш: «Янгын куркынычсызлыгы өчен җаваплы ___________», «Янгын турында түбәндәге телефонга шалтыратырга__________».

III. Эвакуация юлларын карап тотуга янгын куркынычсызлыгы таләпләре

3.1. Архив биналарыннан эвакуацион чыгу юлларыны□ ишекләре ирекле һәм бинадан чыгу юнәлеше буенча ачылырга тиеш (янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документлар таләпләре үтәлми торган ишекләрдән тыш).

3.2. Архив биналарында тыела:

- эвакуация юлында көзгеләр урнаштыру, чын ишекләр белән охшашлыгы булган ялган ишекләр ую;
- үзеннән-үзе ябылучы ишекләрне аык хәлдә калдыру;
- биналарда һәм эвакуацияләү юлларында кешеләрне эвакуацияләргә, янгын сүндерү һәм сигнализация чараларына барырга комачаулаучы җиһазлар һәм башка предметларны урнаштыру;
- эвакуация юлларын ремонтлау өчен янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документлар белән каралган янгын чыгу куркынычы күрсәткечләре югары булган материалларны, шул исәптән декор элементларын куллану.

3.3. Эвакуация юлларында кулланылучы янгын куркынычсызлыгыны□ автономияле һәм электр челтәреннән эшләүче күләмле яктырткыч билгеләре («Эвакуацион (запас) чыгу юлы», «Эвакуацион чыгу юлы ишеге» дигән яктылык күрсәткечләре) һәрвакыт төзек хәлдә булырга тиеш.

Эвакуацион яктыртылу, электр белән тәэмин ителү туктатылгач, автомат рәвештә кушылырга тиеш.

IV. Архив саклагычлар өчен янгын куркынычсызлыгы таләпләре

4.1. Архив саклагычларда азык кабул итү һәм башка ярдәмче бүлмәләр урнаштыру рөхсәт ителми.

4.2. Архив саклагычлар металл стеллажлар белән җиһазландырылырга тиеш.

Ярдәмче яки махсус җиһазлар сыйфатында металл шкафлар, сейфлар, шкаф-стеллажлар, шулай ук металл бүлекләре һәм киштәләре булган бокслар кулланылырга мөмкин.

4.3. Архив саклагычларда стеллаж һәм шкафлар түбәндәге нормаларны үтәп куелырга тиеш:

- стеллаж һәм шкаф рәтләре арасында ераклык (төп үтү юлы) – 1,2 м дан ким түгел;

- стеллажлар арасында ераклык (үтү юлы) – 0,75 м дан да ким түгел;

- стенаға параллель урнаштырылган стёллажлар (шкафлар) белән бинаның тышкы стенасы арасында ераклык – 0,75 м дан да ким түгел;

- бинаны□ тышкы стенасы белән стеллаж яки шкафны□ аркылы киселеме (урап чыгу) арасында ераклык – 0,45 см дан да ким түгел.

4.4. Документларны саклау өчен стеллажларны, шкафларны һәм башка җиһазларны бинаның тышкы стеналарына һәм вентиляцион каналларга якын итеп урнаштыру рөхсәт ителми.

## V. Электр җайланмалары

5.1. Архивларның көч һәм яктырту электр җиһазлары, электр үткәргечләр һәм электр җайланмалары төзек хәлдә булырга тиеш.

5.2. Ток үткәргеч өлешләр, бүлү җайланмалары, аппаратлар һәм үлчәү приборлары, шулай ук төрле типтагы саклагыч җайланмалар, рубильниклар, эшләтеп җибәрү җайланмалары янмый торган материаллардан гына монтажланырга тиеш.

5.3. Барлык электр җайланмалары нормаль эш режимыннан тайпылышлардан һәм кыска ялганыштан сакланырга тиеш.

5.4. Электрүткәргечләре һәм кабельләр белән эшләгәндә, зур күчмә каршылыклар булмасын өчен, эшне опрессовка, эретеп-ябыштыру яки махсус зажимлар ярдәмендә башкарырга кирәк.

5.5. Яктырту электр челтәре, яктырткычлар биналарны□ янучан конструкцияләреннән, эшләнмәләреннән (агач шкафлардан) һәм материаллардан ким дигәндә 0,5 метр ераклыкта булырлык итеп монтажланырга тиеш.

5.6. Архив биналарында вакытлыча электр челтәрләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү рөхсәт ителми (төзелеш һәм ремонт-монтаж эшләрен башкаруны вакытлыча тәэмин итүче электр үткәргечләреннән тыш).

5.7. Күчмә яктырткычлар саклагыч пыяла капкачлар, элеп кую өчен сеткалар һәм элмәкләр белән җиһазланган булырга тиеш.

Бу яктырткычлар һәм башка күчмә приемниклар өчен бакыр сыгылмалы чыбыклар кулланылырга тиеш.

5.8. Эвакуацион һәм аварияле яктырту челтәрендә сүндергечләр яки штепсель разъемларын урнаштыру рөхсәт ителми.

5.9. Эш вакыты тәмамланганнан соң, дежур персонал булмаган биналарда электр җайланмалары һәм электр приборлары электрдан аерылган булырга тиеш. Әгәр бу аларның функциональ билгеләнешенә бәйле булса һәм (яки) эксплуатацияләү буенча инструкция таләпләрендә каралган булса, электр җайланмалары һәм электротехника әйберләре электр көчәнешендә калырга мөмкин.

5.10. Хезмәт биналарында электр белән җылыту приборларын куллану рөхсәт ителә. Эш көне тәмамланганнан соң, электр белән җылыту приборлары электр челтәреннән аерылырга тиеш. Терморегуляторлар һәм җылылык саклау җайланмалары булмаганда яки төзек булмаган очракта, җылыту приборларыннан файдалану рөхсәт ителми.

5.11. Электр җайланмаларын һәм электр челтәрләрен кулланган вакытта тыела:

- изоляциясе бозылган яки саклагыч үзлекләре юкка чыккан электр үткәргечләрен һәм кабельләрне куллану;
- ватык розеткалардан, яктырту һәм тоташтыру тартмаларыннан, рубильниклардан һәм башка электр урнаштыру җайланмаларыннан файдалану;
- электр лампаларын кәгазь, тукыма һәм башка янып китүчән материаллар белән каплау;
- артык көчәнештән һәм кыска ялганыштан саклау өчен кулдан ясалган җайланмалар куллану;
- электр щитлары, электр двигательләре һәм эшләтеп җибәрү аппаратлары янында төрле әйберләр, матдәләр һәм материаллар туплап кую.

## VI. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары

6.1. Янгын сүндерүне беренчел чаралары төзек хәлдә һәм даими әзерлектә булырга тиеш.

6.2. Архив биналары беренчел янгын сүндерү чаралары белән тәэмин ителергә тиеш.

Барлык архив саклагычлар да, зур булмаган янгыннарны, шулай ук янгыннарны башлангыч этабында локальләштерү һәм бетерү өчен, янгын сүндерү җайланмалары белән тәэмин ителергә тиеш.

Беренчел янгын сүндерү чараларының төрләрен һәм санын билгеләгәндә, янучы матдәләрнең физик-химик һәм янгын куркынычы булган үзенчәлекләрен, аларның янгын сүндерү матдәләре белән үзара тәэсир итешүен, шулай ук сакланыла торган биналарның мәйданын исәпкә алырга кирәк.

Технологик җиһазларны ут сүндергечләр белән комплектлау әлеге җиһазларга техник шартлар (паспортлар) таләпләре яки янгын куркынычсызлыгының тиешле кагыйдәләре нигезендә башкарыла.

Бинада янгын сүндергечләрнең төрен һәм кирәкле санын сайлауны аларның янгын сүндерү сәләтенә, чик мәйданга, шулай ук янучан матдәләр һәм материаллар классына бәйле рәвештә башкарырга кирәк:

А классы – нигездә органик рәвештә барлыкка килгән пыскып янучан каты матдәләрнең янгыны (агач, текстиль, кәгазь);

В классы – янучан сыеклыклар яки эри торган каты маддәләр янгыны;

Е классы – электр җайланмалары яну белән бәйле янгын.

Ут сүндергеч тибын (күчмә яки кулныкы) сайлау янгын чыганагының зурлыгыннан тора. Янгын чыганагы зур булганда, күчмә ут сүндергечләрдән файдаланырга кирәк.

Бер янгын куркынычы категориясенә кергән берничә кечкенә бина булганда, кирәкле янгын сүндергечләр саны, әлеге биналарның гомуми мәйданын исәпкә алып, таблица нигезендә билгеләнә.

Перезарядкага җибәрелгән ут сүндергечләр зарядка алган ут сүндергечләргә алыштырылырга тиеш.

Архив биналарын саклаганда, янгын сүндерүче матдәнең рөхсәт ителгән микъдарын исәпкә алып, хладонлы һәм углекислоталы ут сүндергечләрдән файдаланырга кирәк.

Янгын чыганагыннан янгын сүндергечнең урнашу урынына кадәр ераклык 20 метрдан артмаска тиеш.

Объектта урнаштырылган һәр янгын сүндергечнең корпусына ак буяу белән төшерелгән тәртип номеры, шулай ук билгеләнгән форма буенча паспорты булырга тиеш.

Янгын сүндергечләр төзек хәлдә булырга, билгеле бер вакытта (кварталга бер тапкыр) каралып торырга, тикшерелергә һәм тузаннан чистартылырга, шулай ук план-график буенча вакытында зарядкага бирелергә тиеш.

Беренчел янгын сүндерү чараларының булуы һәм торышы турында исәпне махсус журналда алып барырга кирәк.

6.3. Беренчел янгын сүндерү чараларын коридорларда һәм чыгу-керү юлларында урнаштыру кешеләрне куркынычсыз эвакуацияләүгә комачауларга тиеш түгел. Янгын сүндергечләрне күренә торган урыннарда, биналардан чыгу юлларыннан 1,5 метрдан да артмаган биеклектә урнаштыру зарур.

6.4. Янгын сүндерү белән бәйле булмаган хуҗалык һәм башка ихтыяҗлар өчен беренчел янгын сүндерү чараларын куллану тыела.

## VII. Янгын вакытындагы гамәлләрне□ гомуми тәртибе

7.1. Янгын яки яну билгеләре (көек исе, төтен таралу, температура күтәрелү) ачыкланганда архивның һәр хезмәткәре бурычлы:

- бу хакта кичекмәстән янгыннан саклау бүлекчәсенә хәбәр итәргә, шул ук вакытта янгын чыгу урынын атарга һәм үз фамилия□не әйтергә кирәк;
- мөмкинлектән чыгып, кешеләрне эвакуацияләү һәм матди кыйммәтләрне саклап калу буенча чаралар күрергә;

- мөмкинлектән чыгып, беренчел янгын сүндерү чаралары ярдәмендә янгынны сүндерү буенча чаралар күрергә.

7.2. Архивны янгын урынына килгән вазыйфаи заты бурычлы:

- янгын чыгу турында хәбәрне янгын чыгу хезмәтенә кабатларга һәм җитәкчелеккә җиткерергә;

- кешеләр тормышы өчен куркыныч янаган очракта, барлык көч һәм чараларны кулланып, кичекмәстән аларны коткаруны оештырырга;

- янгыннан саклау бүлекчәләрен каршы алуны оештырырга һәм янгын чыганагына барып җитү өчен кыска юл сайлауда ярдәм күрсәтергә;

- янгыннан саклау автомат системасыны (хәбәр итү, янгын сүндерү, төтенне бетерү) эшләвен тикшерергә;

- кирәк булган очракта, электр энергиясен өзүне оештырырга (янгынга каршы яклау системаларыннан тыш), аварияле һәм аның белән чиктәш биналарда вентиляция системаларыны эшен туктатырга, янгын үсешен һәм бинада төтен таралуын булдырмый калуга ярдәм итүче башка чараларны үтәргә;

- бинада, янгын сүндерү һәм бетерү чаралары белән бәйле эшләрдән тыш, барлык эшләрне дә туктатырга;

- янгын сүндерү һәм бетерү чараларында катнашмаган барлык хезмәткәрләрне куркыныч зонадан читкә чыгарырга;

- янгын сүндерүчеләр килгәнче, янгынны сүндерүгә бгомуми җитәкчелек итәргә;

- янгын сүндерүдә катнашучы хезмәткәрләрнең куркынычсызлык таләпләрен үтәвен тәэмин итәргә;

- янгын сүндерү белән бер үк вакытта архив документларын һәм матди кыйммәтләрне эвакуацияләүне һәм саклауны оештырырга.

7.3. Янгын сүндерү бүлеге килүгә, архив җитәкчелеге янгын сүндерү җитәкчесенең барлык күрсәтмәләрен үтәргә, кешеләрне һәм кыйммәтләрне эвакуацияләүдә, шулай ук янгынны сүндерүдә һәм бетерүдә кирәкле ярдәм күрсәтергә тиеш.